Җиһаншина Җәмилә Хаҗиәхмәт кызы,

5 гимназиянең башлангыч сыйныф укытучысы

Тема. Нәрсә ул бәхет?

Максат. Бәхет төшенчәсенең мәгънәсен ачыклау. Балаларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү. Укучыларда рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.

**Җиһазлау:** презентация, мәкальләр язылган карточкалар,“Бәхетле балачак” җыры, аңлатмалы сүзлек, терәк сүзләр, кәрзин, чәчәк рәсеме.

Сыйныф сәгатенең барышы

I. **Мотивлаштыру-ориентлаштыру этабы**

1. Уңай психологик халәт тудыру.

Хәерле көн, укучыларым!

Матур үтсен көнебез!

Көләч булсын йөзебез!

Дөрес, матур утырыйк,

Тырышып җавап бирик!

2. Актуальләштерү.

–Укучылар, әйдәгез парларда шифрны чишеп, бүгенге сыйныф сәгатебезнең темасын ачыклыйк әле.

| | 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|---|
| А | С | Н | И |
| В | Ә | Ю | Л |
| Г | У | Т | Р |

| | 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|---|
| А | Б | И | Е |
| В | Т | Ә | М |
| Г | Х | Ү | Т |

А2В1Г3А1В1 Г1В3 А1В2Г1А3Г3 (НӘРСӘ УЛ БӘХЕТ)

- Әйе, без бүген бәхет турында сөйләшербез. Укучылар, мин “Идеяләр кәрзинен” әзерләп куйдым. Сезнеңчә, бәхет нәрсә икән ул? Шушы сорауга үзебезнең фикерләребез белән уртаклашыйк әле (балаларның җаваплары тыңлана)

- Укучылар, әгәр рәссам булсагыз, “бәхетне” нинди төскә буяр идегез?

- Ә аны ашап карасагыз, тәме нинди булыр икән?

- Әгәр “Бәхет”не күтәрергә кушсалар...(җаваплар тыңлана)

II.**Уку мәсьәләсен кую.**

- Укучылар, бик матур җаваплар бирдегез. Безгә әти-әниләребез, туганнарыбыз бик еш бәхет тели. Безнең барчабыз да бәхетле булырга тели, без моңа омтылып яшибез, шуның өчен көрәшәбез. Бәхет турында күренекле кешеләр кызыклы гына фикерләрен әйтәләр, шагыйрьләр шигырьләр язалар, композиторлар аларга көй чыгаралар, җырчылар аларны башкаралар, ә без исә аларны яратып тыңлыйбыз. Бүген мин сезгә бик матур шигырь алып килдем. Исемен ачыклау өчен бер ребус чишеп алыйк әле (Ребусны парларда чишәләр – “Бәхетле син, кешем”)

- Бу шигырьне укучылар, Татарстанның атказанган укытучысы, Россиянең мәгариф отличнигы, Хезмәт ветераны Равил ага Сәйфетдинов иҗат иткән. Гомере буе укытучы, озак еллар мәктәп директоры булып эшләгән, бик мәгънәле шигырьләр язган. Кызганычка каршы, 2018 нче елда Равил ага Сәйфетдинов безнең арадан китте.

- Ничек уйлыйсыз, кеше кайчан бәхетле була икән? (җаваплар тыңлана)

- Бу сорауга төгәл җавап бирү өчен нишләрбез, укучылар? (җаваплар тыңлана)

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

1. Әсәр өстендә эш.

а) *үрнәк уку (аудиоязма тыңлана)*

- Укучылар, игътибар белән тыңлыйк әле.

б) *үзлектән уку*

-Укучылар, хәзер сүзлекчәдән файдаланып, үзлектән укып чыгабыз.

- Аңлашылмаган сүзләр калмадымы, балалар? (аңлашылмаган сүзләр булса, аңлатмалы сүзлек белән эш оештырыла).

**Бәхетле син, кешем**

Бәхетле син, кешем, кулларың бар,
Тимер ясап, иген игәр өчен;
Бәхетле син, кешем, хыялың бар,
Ерак киләчәккә җитәр өчен.

- Балалар, бу юлларда автор бәхетле кеше турында нәрсә дип әйтә?

Бәхетле син, кешем, хәтерең бар,
Үткәннәргә кире кайтыр өчен;
Бәхетле син, кешем, акылың бар.
Кояш кебек нурлы балкыр өчен.

- Бәхетле булыр өчен кешегә тагынниләр кирәк икән?

Бәхетле син, кешем, зиһенең бар,
Могҗизалар серен аңлау өчен;
Бәхетле син, кешем, иманың бар,
Хак юлыннан читкә таймау өчен.

- Бу юлларны укыгач, нәрсә белдек?

-Укучылар, Равил Сәйфетдинов табигать, чәчәкләрне бик яраткан. Шуңа күрә дәрескә мин бер чәчәк алып килдем һәм исемен “Бәхетле кеше” дип атадым. Ләкин чәчәкнең таҗларын куймадым. Миңа сезнең ярдәм кирәк булачак. Нинди сүзләр язарбыз икән? ( сәламәт булу, хыяллар булу, хәтер булу, акыллы булу, зиһенле булу, иманлы булу). (тактага чәчәкнең таҗлары куела, балаларның җаваплары тыңлана).

**IV. Ныгыту**

- Бәхет турында күп кенә мәкальләр бар.Ә хәзер укучылар, берничә мәкальне җыеп, аңлатып карыйк әле.

- Бәхет пыяла кебек, сакламасаң - уала.
- Акыллы кеше бәхетне көтеп ятмый.
- Үз-үзенә ышанган кеше бәхетле була.

(парларда эшлиләр)

- Бүгенге әңгәмәбезне бер гыйбрәтле хикәят белән тәмамлар идем.

Көннәрдән беркөнне өч бертуган чокырда утырган Бәхетне күрделәр. Агайларның берсе чокыр янына килеп, Бәхеттән акча сорады. Бәхет аңа, әлбәттә, бик күп итеп акча бирде. Агай нык сөенеп өйгә кайтып китте. Икенче туган үз чиратында Бәхеттән матур хатын сорады. Аның да теләген кәнагатьләндерде Бәхет. Агай хатыны белән тиздән күздән югалды. Өченче туган чокырга иелде. "Сиңа нәрсә кирәк?"- дип сорады аннан Бәхет. "Ә сиңа нәрсә кирәк?"- дип кабатлады агай. "Мине бу тирән чокырдан чыгарсаң иде,"- дип җавап бирде Бәхет. Агай кулын сузды да, Бәхетне чокырдан тартып алды. Аннары борылды да, барыр юлын дәвам итте. Ә Бәхет аның артыннан иярде...

Балалар, бәхет ул һәрчак янәшә, шуны онытмасак иде. Бәхетле булу өчен сәламәтлек тә, ярату да, матди яктан тәэмин ителеш тә, рухи байлык, дуслык, гаилә тормышы - барысы да кирәк. Алар бер-берсе белән тоташып бәхет чылбыры тәшкил итәләр.

**V.Рефлексия**

–Балалар, сезне бүген нәрсә шатландырды?

–Нәрсә борчыды?

–Нәрсә сезне уйланырга мәҗбүр итте?

Сыйныф сәгатебезне җыр белән тәмамлыйк. Бәхетле булыгыз!

( "Бәхетле балачак" җыры башкарыла)